**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге Күшәр торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"30" ноябрь 2021 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшәр торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр авылы территориясендә 2022 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшәр авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1.Җирле әһәмияттәге юлларга хезмәт күрсәтү: -
- Комсомольская , Фрунзе урамнарындагы юлларның чокырларын ямау (вак таш сатып алу,җәю һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү)

2) Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:
-лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү;

3) җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту.
- Кошар авылы зиратын куаклардан чистарту һәм төзекләндерү (транспорт хезмәтләре өчен түләү,калдыкларны утильләштерү һәм хезмәт хакы түләү);
- Чүп-чар җыю өчен зират территориясендә каты мәйданчык булдыру һәм ябык контейнер урнаштыру (материаллар сатып алу, хезмәтләр һәм транспорт чыгымнары өчен түләү).
- Авыл территориясен чистарту, хезмәтләр өчен түләү.

4. Җирлек территориясендэ беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:
- электр белән тәэмин итүнең автоном резерв чыганагын сатып алу (бензогенератор -380 В).

5. Чишмәләрне төзекләндерү:
- Чишмәне койма белән әйләндерү (төзелеш материаллары сатып алу эш, транспорт чыгымнары һәм хезмәтләр өчен түләү);

Экономия ясалган очракта, Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетына халыктан җыелган акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Күшәр авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күшәр авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы Сибгатуллин Д.Р.